## Яңа Әлем мәктәбе тарихы

Революциягә кадәр Яңа Әлемдә руханилар укыта торган мәдрәсәләр эшли. Бу мәдрәсәләрдә язарга өйрәтелми, фәкать дин китаплары яттан гына өйрәтелә. Ләкин Яңа Әлемдә күптәннән школа эшли, анда русчага өйрәнәләр. Бу школага якын-тирә авыллардан да килеп укыйлар. Школа дәүләт карамагында була. Школага яңалык ягында торучы, авылның зур мулласы Мансуров Лотфулла җитәкчелек итә. Мансуров Лотфулла зур грамоталы кеше була. Ул Уфа губернасының руханилар җитәкчесе - Мөфтинең ярдәмчесе була. Хәрби званиесе - полк мулласы. Патша тарафыннан зур орденнарга лаек кеше, күп сандагы ореннары һәм медальләре була.

Беренче мәртәбә 1916 нчы елларда әлифба өйрәтелә башлый. Ул әлифба гарәп һәм фарсы телләрендә була. Бу укытуны Лотфулла мулланың кызлары: Мансурова Фәридә, Мансурова Гафифәләр алып бара.

Укулар түбәндәгечә була: иртә белән 1-2 сәгать Лотфулла мулланың хатыны Фатыйма абыстай, соңыннан 2-3 сәгать рус теле, арифметика, география һәм тарих фәннәре укытыла. Бу фәннәрне Лотфулла мулланың уллары: Хәнәфи, Хаккый, Фәйзерахманнар укыта.

Сугыш елларында укыту туктала. Революциядән соң, беренче мәртәбә 1919 нчы елны Мансурова Фәридә (Лотфулла мулла кызы), Аеш авылыннан Хаваз һәм Сарман мулласы кызы (фамилиясе билгеле түгел) укыта. Карабаш ягыннан килгән сәнәкчеләр Мансурова Фәридә белән Сарман мулласы кызын урам буенча таяклар белән кыйнап, мәсхәрәләп йөртәләр. Кыйнауның сәбәбе: яңача укыту алып барган өчен. Сарман мулласы кызы шушы кыйналудан хәлләнә алмый, үлә. Аештан килгән Хафазны шул вакыттагы школа советы булып эшләүче Батталов Имаморза үз йортларының базында яшереп калдыра. Ул исән котылып кала. Сәнәкчеләрдән соң авылда уку өзелә. Уку 1922 нче елны яңадан башланып китә. Уку авылның кулагы Имамгали йортында бара. Укытучы булып, Колын авылыннан килгән, Харрасов Миргазыян эшли. Аның мәктәпкә йөртә торган бер татар теле китабы була. Ул бер бит кәгазьне икегә бүлеп, бер карандашны берничә балага бүлеп

бирә торган була, чөнки уку-язу әсбаплары бик аз булган. Үзләре теләп укырга килгән балалар бик күп була. Елдан-ел укучылар саны күбәя, укытучылар саны да арта. Аннан соң: Шириазданов Габдрахман һәм Габдрахим, Закирова Шәмгый, Шмгулова Мәликә, Закиров Каис һ.б кешеләр укыта.

1922-1927 нче елларда 4 классլы мәктәптә укыйлар. Уку-язу әсбаплары җитәрлек булмый. Мәктәптә 1 глобус, 1 ярымшарлар картасыннан башка күргәзмәлелек булмый.

1929 нчы елдан Яңа Әлемдә ШКМ оеша (колхозчы-яшьләр мәктәбе). ШКМ башта Ишмаметов Бәкер (авылның кулагы) йортына урнаша. Укучылар бу мәктәпкә теләп йөриләр һәм укыйлар. Аңа Сәфәр, Богады, Солтангол, Такталачык, Усы, Теләкәй, Җияш, Шәрип авылларыннан укучылар җыела. Укучылар мәктәп янына яшелчә, җиләк-җимеш утырталар. Укучылар бу эшне теләп һәм яратып башкаралар. Җәйге каникул вакытында мәктәп интернатында укучылар үзләре теләп калып, җиләк-җимеш һәм яшелчәләрне тәрбияләп үстерәләр. Ләкин 1932 нче елның 25 августында кулак малае Ишмаметов Касыйм сөргеннән качып кайтып, мәктәп бинасына ут төртә. Шуннан соң, ШКМ авылда мәктәп бинасы булмаганлыктан, Иске Әлем авылына күчә.

Яңа Әлемдә укып белем алган кешеләр үз заманында авылда авторитет казанганнар. Мәсәлән, Адигамов Борган, Адигамова Саҗидә, Адигамова Зәйтүнә, Адигамов Хәниф, Гарипов Шагали, Малихов Мирзаян һ.б.

Адигамов Борһан 1919 нчы елдан КПСС члены, 17 яшеннән Кызыл гвардиягә языла, совет власте өчен көрәшә. Колхозлар оештыруда һәм кулакларны сыйныф булу ягыннан юк итүдә катнаша. Актанышта исполком председателе булып эшли. Бөек Ватан сугышында майор булып хезмәт итә. 1944 нче елны Румыниядә һәлак була.

Адигамова Саҗидә дә авылда беренче булып комсомол сафына керә. Авылда Гарипов Шагалиләр белән беренче спектакльләрне оештыралар. Колхоз төзүдә актив катнаша. Авылда укый-яза белмәүчеләрне укыта. Шулай ук аларның энеләре Хәниф тә

беренчеләрдән булып пионер сафына керә. 1924-1928 нче елларны башлангыч мәктәпне тәмамлап, 1929 нчы елдан ШКМ да укый. Мәктәпне тәмамлагач, авылда комсомол секретаре булып эшли.

Авылда 1934 нче елдан алып җидееллык мәктәп укучыларга белем бирүдә ярдәм итә. Мәктәптә укучыларга бик күп укытучылар белем һәм тәрбия бирүдә үзләренең тырышлыкларын куйганнар. Балаларга тәрбия бирү өлкәсендә яңа оешма-пионер оешмасы да барлыкка килә. 1928 нче елларда пионер сүзе инде ишетелә башлый. Бу чорда әле аңлату эшләре алып барыла. Ә укучылар әле пионерга керүдән куркалар, чөнки өйләренә кайткач, әбиләре һәм бабайлары орыша торган булганнар. Бу вакытта пионер галстуклары булмаган, ул кызыл материядән генә киселеп эшләнгән. Аны да яхшы укый торган укучыларга гына биргәннәр. Пионер отряды 1935 нче елда ныклап оеша башлый. Пионер отряды составында 26 пионер була. Пионерга кабул итү өченче класстан башлана. Бу елларда укытучы булып, шулай ук пионер эше белән Авзалов Акмалетдин эшләгән.

Ул вакытта иң актив пиоерлардан: Сәетова Тәзкирә, Зәкиев Нәкый, Хуҗина Гөлчирә, Наикова Бану, Галиева Зөбәйдә, Имамова Рәисә. Бу укучылар мәктәпнең 2 нче чыгарылышы була. Ә аннан соң һәр елны пионер сафына күбрәк укучылар керә башлый. Ә Тәзкирә Сәетова 7 нче класста укыганда пионерлар белән эшли. Шулай ук Хафизә Анварова да мәктәптә пионерлар җитәкчесе булып эшли. Пионерлар ул вакытта тантаналы вәгъдәне белмәгәннәр, бары тик, пионерга яхшы укучыны гына алганнар. Нәгыймов Әбугали яхшы укучыларның берсе була. Аңа яхшы укыган өчен муенына кызыл галстук бәйлиләр. Ә өйләренә кайткач, әбисе бик каты ачулана. Ул өйгә кайтканда галстугын яшереп куя торган була, ә мәктәпкә килгәндә тагын бәйли.

Бары тик 1937-1938 нче елларда авылда пионер оешмасы ныклап оеша.

Пионерлар өчен тантаналы вәгъдә тексты барлыкка килә. Пионерга кабул ителү балалар өчен зур дәрәҗә була, алар тагын да тырышыбрак укый башлыйлар, һәрнәрсәдә башка укучыларга үрнәк булырга тырышалар.

Укучылар тырышып белем алган вакытта, 1941 нче елны Бөек Ватан сугышы башлану халыкка, шул исәптән, укытучылар һәм укучыларга зур кайгы китерде. Барлык ир укытучылар Ватанны саклау өчен сугышка киттеләр. Күпчелек укытучылар булып хатын-кызлар гына кала. Ләкин алар авырлыклардан курыкмыйлар. Үз белемнәрен күтәрергә дә вакыт табалар, балаларга да белем бирүдә көчләрен кызганмый эшлиләр.

1939-1941 нче елларда Яңа Әлемдә директор булып Гобәйдуллин эшли. Ул укытучылар коллективын оештыра, укучыларга белем һәм тәрбия бирүне яхшырта. Сугыш башлангач, илебезне фашистлардан саклау өчен, фронтка китә, шунда һәлак була. Аннан соң, директор вазыйфасын Галиев башкара. Ул математика һәм физика фәннәрен укыта. Бу елларда укытучылар: Галиева Сания, Исламов, Гөлҗимал Валиева, Атнагулова, Хамбулова Бания, Галиева Зөбәйдә һ.б.

1943-44 елларда Сабиров директор була. Ул үзе рус теле фәнен укыта. 1944-45 елларда Зәетов директор вазыйфасын башкара. 1945 елдан Агумов Яңа Әлемдә директор итеп билгеләнә. 1945-1950 нче елларда эшли.

1950 елны Әфтәх Гаязетдинов мәктәп директоры итеп билгеләнә. Аның җитәкчелегендәге укытучылар коллективы бик тату эшлиләр.

Хөкүмәтебез соңгы елларда укучыларның өлгереш һәм йөрешен тагын да яхшырту турында елдан-ел кайгыртучанлык күрсәтә. Укытучылар бу бурычны үтәү өстендә эшлиләр, ләкин кимчелекләр дә була әле. Мәсәлән, 1953-54 нче уку елында 274 укучы мәктәптә укый. Шуларның 41е 4-5 кә укый. Өлгермәүчеләр 16. Шуннан 6 укучы класста утырып кала. Күбесе рус теле, математика, ана теле буенча өлгерми. Бу елларда мәктәп директоры Галимҗан Закиров, өлкән пионервожатый Фатыйма Сарварова, завуч Исмәгыйл Мусин иптәшләр була.

*1967 елгы язма*